Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Приволжский авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№ 2 18.02.2025 ел

«Приволжский авыл җирлегендә пиротехник эшләнмәләрдән файдалану мәйданнарын билгеләү турында» 2024 елның 17 декабрендәге 24 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Приволжский авыл җирлеге башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, "Янгын куркынычсызлыгы турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, "Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент" 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Приволжский авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Приволжский авыл җирлеге башкарма комитетының «Приволжский авыл җирлегендә пиротехник эшләнмәләрдән файдалану мәйданчыкларын билгеләү турында» 2024 елның 17 декабрендәге 24 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. беренче карарның беренче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы карары белән пиротехника әйберләрен таратканда һәм файдаланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spassriy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Приволжский авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: С.Г.Спирин